# XVI ЧАКЫРЫЛЫШ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV УТЫРЫШЫ

## К А Р А Р № 25

Баек авылы 29 июль 2021 ел

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләренең бер өлешен Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органнарына тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 4 өлеше, Баек авыл җирлеге Советының 21.09.2020 елгы карары белән расланган Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында килешүләр төзү тәртибе, Баек авыл җирлеге Уставы нигезендә, Баек авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының җирле үзидарә органнарына тышкы мәгълүмат чараларын урнаштыру проектын килештерү, җир эшләрен җитештерүгә рөхсәтләр бирү буенча төзекләндерү өлкәсендәге вәкаләтләрнең бер өлешен бирергә.
2. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Советына карау өчен җибәрергә.
3. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә Мөслим муниципаль районы Советы карары кабул ителгәннән соң 10 календарь көннән дә соңга калмыйча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыруны тапшыру турындагы килешү төзүгә Як булып чыгарга.
4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
5. Әлеге карар басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән соң үз көченә керә.
6. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Совет рәисе, Баек авыл җирлеге башлыгы** **М.Ф. Фахерлегаянов**